СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.07.2022 г. Агрыз № 18-7

«Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2014 елның 09 апрелендәге 32-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында структур һәм кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, муниципаль хокукый актны Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2014 елның 09 апрелендәге 32-4 номерлы карарына кушымта итеп бирелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2014 елның 09 апрелендәге 32-4 номерлы карары белән расланган Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарә вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2020 елның 22 октябрендәге 2-5 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
09.04.2014 №32-4
карары белән расланган
( 13.07. 2022 № 18-7
карары редакциясендә)

**Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2014 елның 09 апрелендәге 32-4 номерлы карарына үзгәрешләр**

**Статья 1**

Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарәчелек вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2014 елның 09 апрелендәге 32-4 номерлы карарына, Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарәчелек вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә (2 нче кушымта):

«

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы Советының
09.04.2014 № 32-4
карарына 2 нче кушымта
( 13.07 2022 № 18-7
карары редакциясендә)

**Әгерҗе муниципаль районында вакантлы идарәчелек вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар резервын формалаштыру комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| **Вәлиев А.Р.** | **Комиссия рәисе**, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгы |
| **Альчикова И.В.** | **Комиссия секретаре**, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар бүлеге башлыгы |
| | **Комиссия әгъзалары:** |
| **Акбашев А.Э.** | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| **Даутова А.Ф.** | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының гомуми бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| **Фәтхетдинова Л.Г.** | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы |
| **Абзалиева Д.З.** | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының дини һәм иҗтимагый оешмалары белән хезмәттәшлек Советы әгъзасы, «Татмедиа» АҖ филиалы «Әгерҗе хәбәрләре» газетасы редакциясе» баш мөхәррире (килешү буенча) |
| **Зудова Г.М.** | Әгерҗе районында Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең җәмәгать ярдәмчесе (килешү буенча) |

»